Республика Татарстан
Глава Тураевского
сельского поселения
Менделеевского
муниципального района
423647, село Тураево,
ул. Центральная. 11А

Татарстан Республикасы
Менделеев
муниципаль районы
Турай авыл жирлеге
башкарма комитеты
423647, Турай авылы,
Узәк урам, 11А

Тел./факс 2-73-31

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

13.11.2023 № 8

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, « Турай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

**Карар бирәм:**

1. 2023 елның 23 ноябре 14.00 сәгатьтә Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыенны уздыру урыны итеп Татар Әхтиялы авылы, Үзәк урам, 9Б йорт адресы буенча урнашкан Татар Әхтиялы иҗтимагый үзәге бинасын билгеләргә
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда Менделеевск муниципаль районының Турай авыл җирлегенең Турай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, I-II төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрне, көндезге бүлектә укучы студентларны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

Материал сатып алу һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл кую.

« Риза» "Каршы"

7. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Турай авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Турай авыл җирлеге
башлыгы Г.Б.Куляшова